**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                                                    КАРАР

_______________                                                                                    № ________

**«2021 - 2028 елларга торак пунктларны төзекләндерү» муниципаль программасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 сентябрендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «2021 – 2028 елларга торак пунктларны төзекләндерү» муниципаль программасын расларга.
2. Актаныш муниципаль районының финанс бюджет палатасына әлеге программаны финанслау мөмкинлеген каралга.
3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.И.Гариповка йөкләргә.

Җитәкче                                                                                    И.И.Габдулхаев

**«2014 - 2020 елларга торак пунктларны төзекләндерү» муниципаль максатчан программасы**

**«2014 - 2020 елларга торак пунктларны төзекләндерү» муниципаль максатчан программасы паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2014-2020 елларга торак пунктларны төзекләндерү» муниципаль максатчан программасы (алга таба текстта-Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 сентябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон |
| Программа җитәкчесе | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп эшләүчесе | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |
| Программаның максатлары | Комплексლы төзекләндерү системасын камилләштерү, Актаныш муниципаль районы территориясендә тәртип, архитектура-сәнгать бизәлеше һәм санитар торышны саклау буенча чараларны тормышка ашыру. Район халкының эшчәнлеге һәм ялы өчен уңайлы шартлар тудыру. |
| Программаның бурычлары | - территорияләрне карап тотуның бердәм тәртибен билгеләү;<br><br>- физик һәм юридик затларның территорияләрен төзекләндерү буенча чараларны тормышка ашыруга җәлеп итү һәм чисталык һәм тәртип саклау өчен аларның җаваплылыгын арттыру;<br><br>- территорияләрне куллану, саклау һәм төзекләндерү буенча контрольне көчәйтү; |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | - 2014-2020 еллар |
| Программаның төп чаралары исемлеге | - территорияләрне төзекләндерү;<br><br>- электр тапшыру линияләрен төзү;<br><br>- коймаларны реконструкцияләү һәм ремонтлау, балалар мәйданчыкларын, спорт мәйданчыкларын төзекләндерү;<br><br>- юлларны, җәяүлеләр күперләрен ремонтлау һәм төзү;<br><br>- сулыкларны төзекләндерү |
| Программаның төп | - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты; |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | |
|---|---|
| чараларын башкаручылар | - предприятие һәм оешма җитәкчеләре (килешү буенча);<br><br>- авыл җирлекләре. |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | программаны тормышка ашыру өчен финанслауның гомуми күләме 193,25 млн. сум тәшкил итә, кушымта нигезендә. |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны һәм идарә итүне оештыру системасы | - Программаның гомуми җитәкчелеге һәм аны гамәлгә ашыру барышын программа җитәкчесе контрольдә тота. Программа җитәкчесе тарафыннан ел саен чираттагы календарь елына программаның беренче чираттагы чараларын аныклау һәм киләсе елга чаралар исемлеген проектлау үткәрелә.<br><br>Программаны гамәлгә ашыруның барышын контрольдә тоту программа чараларын башкаручыларның гамәлләренә ел саен мониторинг ясау системасыннан гыйбарәт. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | - Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә халык күпләп җыела торган урыннар территорияләрен төзекләндерү, юл полотносын ремонтлау, балалар һәм спорт мәйданчыкларын төзекләндерү, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү, Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәйкәл-обелискны яңарту, башка чаралар. |

## 1. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысуллары белән хәл итү кирәклеген нигезләү.

Әлеге Программа торак пунктларны төзекләндерү, яшелләндерү, санитария торышын яхшырту һәм архитектура-сәнгать бизәлеше чараларын гамәлгә ашыру өчен төп чара булып тора.

Торак пунктларның тышкы төзекләндерү объектларының күбесе, җәяүлеләр зоналары, ял итү зоналары, юллар кебек, ремонт һәм реконструкцияләүгә мохтаҗ.

2013 ел дәвамында җирлекнең торак пунктларында юл өслеген ремонтлау буенча билгеле бер эш башкарылды, балалар мәйданчыклары яңартылды, урналар куелды, яшелләндерү эшләре алып барыла.

Төзекләндерү проблемаларын хәл итүгә программалы-максатчан якын килү кирәк, чөнки Актаныш муниципаль районын төзекләндерүнең комплекслы төзелеш системасыннан башка, район халкының ялын һәм эшчәнлеген уңайлы шартларда тәэмин итүдә нинди дә булса мөһим нәтиҗәләргә ирешү мөмкин түгел. Район башкарма комитеты, предприятие, учреждение, халыкның тормыш-көнкүрешен тәэмин итүче һәм төзекләндерү белән шөгыльләнүче эш-гамәлләрен төгәл килештерү мөһим. Төзекләндерү перспективаларын билгеләү куелган бурычларны хәл итүгә акчалар тупларга ярдәм итәчәк, ә төзекләндерүнең аерым элементлары агымдагы ремонтлауга акча сарыф итмәскә мөмкинлек бирәчәк.

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләрендә, ташландык, хуҗасыз транспорт чараларыннан азат итү буенча чаралар күрү күздә тотыла.

Программаны финанс яктан тәэмин итү Актаныш муниципаль районы бюджеты хисабына гамәлгә башкарыла.

## 2. Программаның төп максатлары, бурычлары, гамәлгә ашыру вакыты.

Программаның максатлары һәм бурычлары түбәндәгеләр:

- тәртип, төзекләндерү, архитектура-сәнгать бизәлеше һәм санитария торышын саклау чараларын тормышка ашыру;
- халыкның яшәве өчен уңайлы мохит формалаштыру;
- ишегалды территорияләрен төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү, торак йортларга якын килү һәм керү юлларын яхшырту;
- территорияләрне карап тотуның бердәм тәртибен билгеләү;
- физик һәм юридик затларның территорияләрен төзекләндерү буенча чараларны тормышка ашыруга җәлеп итү һәм чисталык һәм тәртип саклау өчен аларның җаваплылыгын арттыру;
- территорияләрне куллану, саклау һәм төзекләндерү буенча контрольне көчәйтү;
- ишегалды, квартал эчендәге машина юлларын норматив таләпләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган дәрәҗәгә кадәр торгызу һәм транспорт-эксплуатацияләү торышын күтәрү;
- хуҗалык, балалар һәм спорт мәйданчыкларын яңа кече архитектура формалары белән төзү һәм төзекләндерү.

Программаны тормышка ашыру вакыты – 2014-2020 еллар.

## 3. Программа чаралары системасы.

Максатчан программа чараларына түбәндәгеләр керә:

- территорияне җыештыру, шул исәптән территорияне чүп-чардан, пычрактан, кардан даими чистартып тору, чүп-чар чыгару, яшел үсентеләрне карау;
- тышкы төзекләндерү элементларын карап тоту;
- муниципаль берәмлек территориясен яшелләндерү;
- юлларны карап тоту һәм эксплуатацияләү;
- муниципаль берәмлекләрнең торак пунктларын яктырту;

- программаны финанслау күләмен билгеләү һәм раслау;

- программаны, мәгълүмати-аналитик материалларны гамәлгә ашыру хисабын әзерләү;

- программаның максатларын һәм бурычларын хәл итүне яктырту, программаны гамәлгә ашыруның барышы турында эшләрне халыкка җиткерүне оештыру.

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә халыкның ялы һәм эше өчен уңайлы шартлар тудыру көтелә.

Программаның нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр буенча бәяләнә:

- Актаныш муниципаль районы халкын төзекләндерү эшләренә җәлеп итү проценты;

- авыл җирлеге предприятиеләрен һәм оешмаларын төзекләндерү эшләренә җәлеп итү проценты;

- җирлекне төзекләндерүне тәэмин итүче предприятиеләрнең һәм инженер челтәрләре хуҗаларының үзара хезмәттәшлеге дәрәҗәсе;

- Актаныш муниципаль районының төзеклеге дәрәҗәсе (җирлекнең камилләштерелгән өслекле автомобиль юллары, тышкы яктырту челтәрләре, яшел үсентеләр, балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары белән тәэмин ителеше).

## 4. Программа чараларын ресурслар белән тәэмин итү.

Программа чараларын финанслау муниципаль бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла. 2014 - 2020 елларга планлаштырылган чыгымнарның гомуми суммасы – 193,25 млн. сум.

## 5. Программаны тормышка ашыру механизмы.

Программа чараларын гамәлгә ашыру, гамәлдәге законнар нигезендә, программа паспортында күрсәтелгән төп чараларны башкаручылар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Әлеге программаны тормышка ашыруның төп координаторы - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты.

## 6. Программа белән идарә итүне оештыру, аны тормышка ашыру барышын контрольдә тоту.

Программа чараларын вакытында һәм сыйфатлы үтәү өчен, аны тормышка ашыру өчен бүлеп бирелә торган финанс чараларыннан рациональ файдалану «Башкаручылар» графасында күрсәтелгән оешмалар һәм ведомстволар җаваплы.

## 7. Программаның көтелгән соңгы нәтиҗәләре.

Программалы чараларны гамәлгә ашыру, балалар һәм спорт мәйданчыкларын төзекләндерергә, рөхсәтсез чүплекләрне бетерергә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл-обелискны яңартырга мөмкинлек бирәчәк. 21,0 км юлны төзекләндерергә, янгын сүндерү сулыкларына илтә торган юлларны тәртипкә китерергә. Территорияне яшелләндерергә, ел саен 3000 агач һәм куак утыртырга.

Актаныш муниципаль районы территориясендә чисталык һәм тәртип саклауга карата муниципаль берәмлек халкына мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү.

**«2014 - 2020 елларга торак пунктларны төзекләндерү» муниципаль максатчан программасының төп чаралары**

| № т/б | Чаралар | Еллар буенча чаралар үтәлеше | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| | | млн. сум | млн. сум | млн. сум | млн. сум | млн. сум | млн. сум | млн. сум | млн. сум |
| 1 | Автомобиль юлларын һәм инженерлык корылмаларын карап тоту. Юлларны, кюветларны, җәяүлеләр юлларын, күперләрне, тротуарларны төзекләндерү. | 18,03 | 4,82 | 5,3 | 5,83 | 6,42 | 7,05 | 7,76 | 8,54 |
| 2 | Торак пунктларның урамнарын яктырту. | 5,92 | 5,91 | 6,5 | 7,15 | 7,86 | 8,65 | 9,52 | 10,47 |
| 3 | Җирлектәге торак пунктларны яшелләндерү һәм яшел үсентеләрне карау, агач һәм куакларны кисү, агарту, яшел үсентеләр утырту, бакчаларда, клумбаларда чәчәкләр утырту. | 4,38 | 3,0 | 3,3 | 3,63 | 3,99 | 4,39 | 4,83 | 5,31 |
| 4 | Җирләү урыннарын оештыру һәм карап тоту. | 0,09 | 0,52 | 0,57 | 0,63 | 0,69 | 0,76 | 0,84 | 0,92 |
| 5 | Санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү, территорияләрне чүп-чардан, пычрактан чистарту. | 0,52 | 0,24 | 0,26 | 0,29 | 0,32 | 0,35 | 0,39 | 0,43 |
| 6 | Торак пунктларның урамнарын кардан чистарту, чүп-чар чыгару. | 2,1 | 2,3 | 2,53 | 2,78 | 3,06 | 3,37 | 3,7 | 4,07 |
| 7 | Контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм контейнерлар сатып алу | 0,6 | 0,20 | 0,22 | 0,24 | 0,27 | 0,29 | 0,32 | 0,35 |
| 8 | ташландык, хуҗасыз | 0 | 0,05 | 0,05 | 0,06 | 0,07 | 0,07 | 0,08 | 0,09 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | транспорт чараларыннан азат итү буенча чаралар | | | | | | | | |
| | Нәтиҗә: | 31,64 | 17,04 | 18,73 | 20,61 | 22,68 | 24,93 | 27,44 | 30,18 |
| Барысы: | | | 193,25 | | | | | | |

Лист согласования к документу № ПР-226 от 17.11.2020
Инициатор согласования: Салимов Д.З. Начальник юридического отдела
Согласование инициировано: 16.11.2020 08:36

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Габдулхаев И.И. | | Подписано 17.11.2020 - 09:42 | - |